| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 30 октябре г. Буинск 90-п номерлы

Буа муниципаль районының наркотикларга
каршы көрәш комиссиясе турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 октябрендәге 1374 номерлы Указы нигезендә (2018 елның 11 октябрендәге үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре турында» 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы Указы нигезендә (2019 елның 9 октябрендәге үзгәрешләр белән)

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа муниципаль районы башлыгының 2008 елның 01 февралендәге 15 номерлы «Буа муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия төзү турында» (алга таба-Нигезләмә) карары белән расланган, Буа муниципаль районының наркотикларга каршы көрәш комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 10 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия әгъзалары утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм комиссия рәисе кул куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзасы, утырыш беркетмәсенә мәҗбүри кушылырга тиешле, утырыш уздырылган көннән соң биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә торган үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

Комиссия рәисе тарафыннан расланган, Комиссия карарлары, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, Буа муниципаль районының башкарма хакимият органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, авыл җирлекләре башлыклары тарафыннан утырыш уздырылган көннән соң 15 эш көне эчендә мәҗбүри каралырга тиеш.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдинов